КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 июль г.Казань № 546

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 2020 ел, 11 декабрь, 1130 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 2020 ел, 11 декабрь, 1130 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының бюджет учреждениеләре тарафыннан әлеге учреждениеләрнең түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алган керемнәреннән административ-идарә персоналының эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнар күләме бу карарның 1 пункты нигезендә эш хакын түләүгә җибәрелә торган әлеге керемнәр күләменең 30 процентыннан арта алмый.»;

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы автоном учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә әлеге учреждениеләрнең түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәреннән административ-идарә персоналының эш хакын түләүгә әлеге керемнәр (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) күләменең иң күбе 30 процентын җибәрергә.».

2. Бу карар 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин